
”

# “Тарих битләрендә гаиләм язмышы”



Автор:
Латыйпова Энҗе Фәрид кызы, 6 нчы сыйныф,
Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы,
МБГУ Исәнбай урта гомуми белем бирү мәктәбе.
.

**Максат:** иксез – чиксез сугыш тарихы битләренә гаиләмнең керткән өлешен, җәмгыятьтә тоткан ролен ачыклау.

**Мәсьәләләр:**

- Латыйповларның гаилә әгъзаларының тормышы юлларына күзәтү ясау. Сәет бабамның сугышта үткән хәрби юлын ачыклау.
- Сугышта хәбәрсез югалган Садыйк бабамның язмышын өйрәнү.

**Эзләнү объекты:** сугыш елларында минем гаиләм.


**Гипотеза:** минем әби- бабаларым сугыш елларының катлаулы сынауларын лаеклы үтте.

**Эш алымнары:** тарихи чыганакларны анализлау, чагыштыру, гаилә әгъзалары белән әңгәмә кору.

# Көчле рухлылар.




Сәет бабай һәм Мөнҗия әби




«Республиканың авыл хуҗалыгында В. И. Гагановага иярүчеләр дә табылды.

Шулар арасында савымчылардан Красный Бор районының Фрунзе исемендәге колхозыннан М. Газизова шулай эшләде…»



1958 елны ук республика авылларында коммунистик хезмәт
коллективлары һәм ударниклары исемен алу өчен ярыш җәелеп
китте. Кайбыч районының Фрунзе исемендәге һәм Питрәч райо-
нының «Искра» колхозларының товарлыклы сөт фермалары кол-
лективлары бу ярышның башлап йөрүчеләре булдылар. Комму-
нистик хезмәт ударнигы исемен яулап алу өчен беренче булып
көрәшне Актаныш районы Киров исемендәге совхозның дуңгыз
караучысы Зөлфирә Каһирова башлап җибәрде. Ярышка кушы-
лып, ул елга 700 дуңгыз симертергә сүз бирде. Тырыш хезмәте,
эшенә иҗади караву нәтиҗәсендә ул йөкләмәсен арттырып үтә-
де. З. Каһирова 1959 елда 873, 1960 елда 1300 дуңгыз симертте
һәм дәүләткә 1700 центнер ит тапшырды.
Коммунистик хезмәт ярышына А. С. Садыйкова җитәкчелек
иткән «Комсомол» совхозы үрдәк караучылары бригадасы, «Чи-
стай» совхозының Мария Бурлако җитәкчелегендәге ак төлкеләр
фермасын караучылар һәм башка коллективлар кушылды.
ТАССРның 40 еллыгы алдыннан коммунистик хезмәт ярышы-
на Югары Ослан районы «Коммунизмга юл» колхозының алдын-
гы коллективы, аннары «Бөреле» һәм «Кошаково» совхозлары-
ның работниклары кушылды.
1961 елның сентябренә республика авылларында коммуни-
стик хезмәт өчен ярышка катнашучыларның саны 17 мең кешегә
җитте. Бу ярышта ике колхозның, дүрт совхозның коллектив-
лары, меңнән артык фермалар, бригадалар, бүлекләр катнашты.
90 коллектив коммунистик хезмәт бригадалары булды, алар ара-
сында Лаеш районы Нариман исемендәге колхозның товарлык-
лы сөт фермасы, Нырты совхозының мөгезле эре терлек ферма-
сы; Буа районының «Коммунизм» колхозы трактор бригадасы
һәм башкалар бар иде. Меңнән артык авыл хезмәтчәннәре ком-
мунистик хезмәт ударниклары исемен яулап алдылар.
Республиканың авыл хуҗалыгында В. И. Гагановага иярүче-
ләр дә табылды. Шулар арасында Минзәлә районының Ленин
исемендәге колхоз председателе урынбасары коммунист В. А. На-
заров та бар иде, ул арттa калган бригаданың бригадиры булып
күчте. Савымчылардан Красный бор районының Фрунзе исемен-
дәге колхозыннан М. Газизова, Алабуга районы «Труд» колхо-
зыннан Р. Макарова, Куралово совхозыннан А. П. Хваткова һәм
республика авыл хуҗалыгының уннарча башка хезмәтчәннәре
шулай эшләделәр.
Дәүләтнең ярдәме, колхозларның һәм совхоз эшчеләренең фи-
дакарь хезмәте нәтиҗәсендә авыл экономикасы елдан-ел ныгый
барды. 1961 елны колхоз һәм совхозлар продукциясе 1958 елдагы
301 миллион сум урынына 455 миллион сумнан арттыракка җи-
тештерделәр. Колхозларда һәм совхозларда мөгезле эре терлек-
ләр саны өч ел эчендә 300 мең башка, дуңгызлар 365 меңгә, са-
рыклар 178 меңгә үсте. Чәчүлек мәйданы 325 мең гектарга дияр-
лек артты. Республика авыл хуҗалыгында тракторлар, бөртекле
ашлык комбайннары, йөк автомобильләре һәм башка төрле тех-
627
40*



Бабам **Латыйпов Сәет Шәех улы** 1926 нчы елнын 24 нче декабрендә крестьян гаиләсендә туа. Сәет бабай үзлегеннән укырга, алты яшендә Садыйк абыйсыннан язарга да өйрәнгән. Ул, китаплар булмаганлыктан, үзәк урамга көненә икешәр тапкыр барып, колхоз лозунгларын укыган. Колхозлашу чорларында бик күп кешеләр, гариза язып бирүне сорап, алты яшьлек малайга килә торган булганнар. Кечкенә Сәет дистәләрчә гаризалар язган. Башта колхозга алуларын сорап язса, соңыннан колхоздан чыгаруларын үтенгән гаризалар күбәеп киткән. Бу вакыйгадан соң колхоз рәисе Шәех бабайга малаен бераз тыярга кушкан. Үзенең тырышлыгы, үҗәтлеге, яңалыкка омтылышы көчле булганга бабам тормышта күп нәрсәләргә ирешкән. Үсмер егеткә колхоз зур ышаныч белән трактор тапшырган. Сугышка киткәнче ул корыч атыннан аерылмаган.……………………………………………………



Әтисе **Шәех Латыйф улы** урта хәлле игенче була. Колхозга кергәч, тырышып, башкаларга урнәк булып, үз-үзен аямыйча, чын куңелдән фидакарьләрчә эшли. Бригадир булып та урнаша. Партиягә кереп, күп еллар «Комбайн» исемендәге колхозның идарә рәисе булып эшли. Колхозчылар тарафыннан ихтирам ителә, авылның иң абруйлы кешесенә әверелә. Авыл советы члены (хәзергечә депутаты) итеп сайлана. Авылдашлар аны үз максатына ирешүчән, акыллы, хезмәт сөючән, дөреслекне яратучан булганы өчен бертавыштан авыл советы рәисе итеп сайлыйлар. Ун елдан артык алмашсыз авыл башы итеп тоталар.……………………………………………………

Бабамның әнисе **Зәрифә әби** чисталык, пөхтәлек буенча Исәнбайда дан тоткан әби булган. Анын таләпчән, горур, тырышлыгына бөтен авыл сокланган. Шәех бабай белән Зәрифә әбинен 12 балалары булган, ләкин кечкенә чагында ук тугызы улгән. Бары тик өчесе: Садыйк, Сәет, Өммегөлсем генә исән калганнар.…………………………

# Бабамның үткән юлы







1. Сәет бабай 17 яшендә үзенең сугышчан юлын Сарапул шәһәренең хәрби училищесыннан башлап җибәрә. Аның бик тә очучы буласы килә. Ләкин ниндидер сәбәпләр аркасында аны Ерак Көнчыгышка танк училищесына җибәрәләр.
2. 1943нче елның 5нче июлендә атаклы Курск дугасы бәрелешендә катнаша. Германия гаскәрләре алдына Курск тирәсендәге совет көчләрен чолгап алу һәм юк итү бурычы куела. Бу операция «Цитадель» исеме ала.
3. 1943нче елның июль, август, сентябрь айларында Төмән госпиталендә үткәрә. Соңрак аны Петровск- Забайкальск госпиталенә кучерәләр.
4. 1945нче елның 9нчы августында аларның хәрби часте 2 нче Ерак Көнчыгыш фронты составында Квантун гаскәрләренә каршы һөҗүм операциясен башлый. Ул Япон сугышында катнашып, Цицикар, Харбин, Муданьцзян, Чанчунь, Шэньян, Порт- Артур  кебек шәһәрләрен азат итәләр.
5. 1948 нче елда төзелеш взводы командиры итеп билгеләнә һәм Мәскәү Дәүләт Университеты төзелешенә җибәрелә.
6. 1950 нче елда гына туган авылы Исәнбайга әйләнеп кайта.

# Садыйк бабай





СССР
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ОРДЕНА ЛЕНИНА
СОЮЗА ОБЩЕСТВ
КРАСНОГО КРЕСТА И КРАСНОГО ПОЛУМЕСЯЦА

100031, Москва, К-31, Кузнецкий мост, д. 18/7 Телефон 221-71-75

При ответе ссылайтесь на наш номер

№ 28268/5 Москва, 3 октября 1988

Адрес для телеграмм: Москва – ИКРЕСТПОЛ

Уважаемый тов. ЛАТЫНОВ Саит Шаихович !


Сообщаем, что по сведениям Центрального Архива МО СССР, куда мы обращались по вопросу установления судьбы Вашего брата – рядового ЛАТЫНОВА Садыха Шаиховича, 1920 г.р., он умер от ран 20.04.1945 года и похоронен первоначально в г.Колов, бывшей Германии, сейчас – ПНР, г. Ковалюв(находящийся в аналогичным названием в двух воеводства: Щецинском и Гожовском).

Одновременно сообщаем, что нами направлен запрос в Польский Красный относительно выяснения сохранности его могилы и увековечения памяти на одном из советских воинских кладбищ в ПНР. По получении ответа из-за рубежа результат Вам будет сообщён дополнительно.

Для сведения сообщаем, что наведение сохранности могил на территории ПНР осуществляется в течение года и более.

В завершении сообщаем, что выяснение судьбы Вашего брата связано с просьбой польской патриотки, лично обратившейся к нам в Управление, которая во время Великой Отечественной войны спасла от верной гибели четырех советских военнопленных(в том числе и Вашего брата), которые бежали из плена, она бескорыстно оказывала им помощь и помогла перейти линию фронта и сражаться в дальнейшем против фашистов.

Зам.Начальника Управления по розыску
Исполкома СОКК и КП СССР А.К.Криштафович




Копия

Тов. Фидлеру Александру!

От командиров Рабоче-крестьянской Красной Армии:
-№1.Капитана Тохтамирова Петра Георгиевича.
2.Мл.лейт. Аникина Салим
3. Мл.ком. Латыпова Садик Шаихович
4 Курсан.истр. отряд. № 132 ШАМЕНЕВ Хатип Назмиевич

Мы, командиры РККА благодарим за оказанную нам помощь в укрытии нас от рук фашистских извергов и переправу нас через границу протектората. Мы просим командование РККА найти в первые зашедший в гор.Лодзи обратиться к тов. Фидлеру А. за помощью в борьбе и ликвидации остатков фашизма в городе. Одновременно просим оказать всемерную помощь в жизни и в работе тов. Фидлеру А., как преданному гражданину делу нашего народа. Мы Фидлера А. знаем более года, воёвремя он оказывал нам помощь в блрьбе с фашизмом, в пропагандировании идей Сов. власти. Оказывал помощь в переправе 4 человек военнопленных бойцов, работавших в 3-м отделе ДВМ, а также в переправе нас через границу и указание путей, несмотря на то, что мы в качестве военнопленных находились в глубоком тылу немецких оккупантов.

А также оказать помощь гражданке Майхшановской Станиславе, которая непосредственно принимала участие в переправе нас через границу в протекторат, кроме того в течение 3-х дней укрывала нас в своей квартире от Гестапо. В чем и собств.ручно



подписываемся:

1.(подпись)Тахтамирова Петр
2.Латыпова Садык
3.Аникина Сэлим
4.~~Шаменов~~ Шаменов Хатип (handwritten name uncertain)


Адреса: Тохтамиров П.Г.г.Армавир Краснодарский край, Комсомольская 155.
Аникин С. –Омская область2Вагайский с/с
ЛатыповС.– ТАССР,Красноборский р-н, дер. Сымбоево.
Шаменев Х.– ТАССР, Кам.-Устинский р-н, село Уразмиево.

9.7.44 .

С оригиналом верно: инструктор Управления по розыску Исполкома СОКК и КП СССР –
Л.П.Четвертак

Хатта Кызыл Армия командирлары капитан Тахтамиров Петр Георгиевич, кече лейтенант Аникин Сәлим, кече командир Латыйпов Садыйк Шәехович, 132 нче истребительләр курсанты Шаменев Хатип Назмиевичләр, Фидлер Александрга фашизмга каршы көрәштә күрсәткән ярдәмнәре һәм фашист тоткынлыгыннан качарга булышканнары өчен рәхмәт белдерәләр һәм Җирле хакимияттән Фидлер Александр белән Майхшановска Станиславага, үзләрен өч көн буе, гестаподан яшереп, үз квартирасында тоткан, чик үтәргә булышлык иткәннәре өчен ярдәм күрсәтүләрен үтенәләр. Хат 1944 нче елның 9 нчы июлендә язылган.


# Серле йомгак сүтелә



Сәлим Аникин

МУСА ӘЙТКӘНЧӘ

Г. Кашшаф
“Муса турында истәлекләр”
Сәлим Аникин “Муса әйткәнчә”




Р. Мостафин
“Өзелгән җыр эзеннән”

# Йомгаклау

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсем килә: Латыйповлар нәселе илебезне фашистлардан азат итүдә үзләреннән зур өлеш кертгәннәр, иксез – чиксез сугыш тарихы битләренә уелып калганнар.

## Кулланылган чыганаклар:

1. СССР башкарма комитеты Ленин орденлы Халыкара Кызыл Хач һәм Кызыл Ай Җәмгыяте хаты., 3 октябрь, 1988 ел.
2. СССР башкарма комитеты Ленин орденлы Халыкара Кызыл Хач һәм Кызыл Ай Җәмгыяте хаты.,22 август, 1989 ел.
3. Хат. Януш Пшимановский. Польша. Память. Второе издание.1989 г.

## Әдәбият исемлеге

4. Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр өч томда. 2 том. Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр. – Казан: Таткнигоиздат, 1955.

5. Муса турында истәлекләр. Төзүче һәм әдәби эшкәртүче Гази Кашшаф. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1964.

6.Мустафин Р.А. По следам оборванной песни.- Казань: Татар. Кн.изд-во, 2004 г.

7. Татарстан АССР тарихы.- Казан:Татарстан китап нәшрияты, 1970 .

8. С. Хәким Җылы сүз.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1968 .